Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

№ 5 01.04.2016ел

Хөкем ителгәннәрнең җәзасын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм объектларны билгеләү турында

РФ Җинаять кодексы нигезендә 49 статьясының 1 өлеше, 25 статьясының 1 өлеше нигезендә. РФ Җинаять башкарма кодексының хөкем ителгәннәр тарафыннан Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә хөрмәтле мөнәсәбәт формалаштыру максатларында Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ::

1. Яңа Ибрай авыл жирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә: Яңа Ибрай авылы җинаять – башкару инспекциясе белән килешү буенча.
2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә - торак пунктны төзекләндерү һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, юллар һәм буалар буендагы куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, җинаять-башкару инспекциясе белән килешү буенча юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.
3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Ф.Х.Кәбиров